*Хөснетдинов Д. Х. (КФУ, Казань*
*Галаутдинова А. М. (КФУ, Казань)*

# ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУДА МИЛЛИ-МӘДӘНИ КОМПОНЕНТ

**Аннотация:** В данной статье описаны особенности использования национально-культурного компонента в преподавании татарского языка. Так как в современной лингвометодике отмечается необходимость включения данного компонента в преподавании языка как одного из важнейших путей передачи национальной культуры и формирования личности. Национальная культура несет в себе большой социально-педагогический потенциал в преподавании предметов гуманитарного цикла.

**Ключевые слова:** коммуникация, мотивация, компонент, национальная картина, методика.

**The national-cultural component in the teaching of the Tatar language**

**Abstract:** This article describes the features of the use of the national-cultural component in the teaching of the Tatar language. As in the modern lingvomethodic the necessity of inclusion, of this component in language teaching as one of the most important ways of transmission of national culture and identity formation. National culture has a big social and pedagogical potential in teaching humanitarian subjects.

**Key words:** communication, motivation, component, national picture, methodica.

Мәктәпләрдә татар телен укыткanda милли-мәдәни компо-

нентларны уңышлы куллану, беренчедән, этно-мәдәни, тел, тарихи-географик, коммуникатив юнәлештәге укыту материалына бәйле. Укыту материалының эчтәлеге методик максатка яраклылык күзлегеннән чыгып туплана. Ул исә, үз чиратында, икенче телдә аралашырга өйрәтүгә һәм балаларны татар халкының рухи һәм матди культурасына тартуга ярдәм итә. Милли мәдәни компонентларны тикшерүдә күп галимнәребез көч куйган. Методистлар бу өлкәгә карата үз юнәлешләрен биреп киләләр.

Татар теле дәресләрендә сүзләренең милли мәдәни катламы укучыларга татар мәдәниятенең югары дәрәҗәдәге кыйммәтләрен үзләштерү буенча танып белү эшчәнлеген активлаштыру максатларында кирәк. Татар булмаганнарга татар телен укыту зарурлыгы культурологик материалны системалаштыруны таләп итә. Татар теле дәресләрендә милли мәдәни компонентны кертү белем бирүне мотивацияләүнең тәэсирле факторларыннан берсе булып тора. Һәм мәдәни компонент лексика, фразеология, афористика өлкәсендә бигрәк тә ачык күренә.

Телгә өйрәтү дөньяның яңа милли картинасын формалаштыруга ярдәм итүче белемнәр белән бәйле. Укучыларның әлеге белемнәрне географик характердагы белешмәләрдән, тарихи вакыйгалар, көнкүреш, тел берәмлекләреннән туплана. Алар татар теленең культуроведик аспектына һәм милли мәдәни мәгънәгә ия.

Гомумдидактик һәм тәрбияви максатларга ирешү өчен, укучыларның акыл хезмәте күнекмәләрен булдыру; татар сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, әңгәмә корырга, фикер йөртергә, хәбәр итәргә күнектерү белән беррәттән татар дөньясына караган милли традицияләр, ризыклар, бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру һ.б. турында мәгълүмат җиткерү сорала. Тәрбияви максат балаларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәниятен һәм сәнгатен хөрмәт итәргә өйрәтү һәм төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

Дәресләрдә этнокультурологик материал төрле чаралар белән кертелергә тиеш. Мәсәлән, уеннар, викториналар, техник чаралар, күрсәтмәлелекләр кулллanып аңлату яки тыңлату, театраль күренешләр күрсәтү, аулак өйләр, биюләр, җырлар, табышмаклар куллану һәм башка шундый чаралардан файдалану уңышлы итеп карала.

Кайбер алымнар кулланып эшләү ысуллары да ти-

ешле нәтиҗәләргә китерергә мөмкин:

1. Уку материалын матди һәм рухи мәдәнияткә, иҗтимагый һәм гаилә-туганлык мөнәсәбәтләренә, декоратив-гамәли иҗатка караган сүзләр белән баету.

2. Язма эшләр (диктант, инша, хикәя) текстындагы милли юнәлешне чагылдырган сүзләр.

3. Тәрҗемә сүзлекләр белән эзләнү-танып белү эше.

4. Татар халкының шактый билгеле булган канатлы сүзләре һәм әйтелмәләренең мәдәни функцияләрен ачыклау.

5. Мәкаль һәм әйтемнәрнең мәгънәләрен ачыклауга юнәлдерелгән иҗади бирмнәр үтәү.

6. Музейларга, күргәзмәләргә экскурсияләр, ахырдан хикәяләр итеп оештырырлык, күргән һәм ишеткәннәрне гомумиләштерү максатларында, татарча спектакльләр һәм концертлар карау.

7. Укытучы үз фантазиясенә дә таянып эшләрә тиеш. Укытучы дәрестә этнокультурологик белемне арттыру максаты белән кулланган укыту алымнары һәм укыту чаралары милли мәдәни үзенчәлекләргә, укучыларда халыкның сакланып калган милли мәдәни хәзинәләренә мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Бу укучыларда милли үзаң һәм милли мәдәният формалаштыруга, шулай ук башка халыкларның мәдәни мирасына хөрмәт тәрбияләүгә булышучы чараларның берсе булып тора. Үз эшен яратып башкара торган укытучы балаларда, башкаларны да рухи баета алырлык чын, ихлас, соклана һәм ярата белүче саф күңелле кешелек сыйфатлары тәрбияләргә тиеш.

Боларны тормышка ашыру максатыннан, алда санап үтелгән чаралардан файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, дәресләрдә уен рәвешендә төрле уеннарны кертергә мөмкин: «Ак калач», «Йөзек салыш» һ.б. Әлбәттә, бу уеннар дәрес буена түгел, ә билгеле бер өлешендә генә кулланылырга мөмкин.

Төрле формадагы театраль күренешләр дә укучыларда кызыксыну һәм соклану хисе тәрбияли. Мәсәлән, аулак өй күренешләре, спектакльләрдән өзекләр, сабантуй, төрле йола һәм календарь бәйрәмнәрне дә кертергә мөмкин.

Шулай ук дәресләрдә аудио һәм видео чаралар ярдәмендә җырлар, уеннар, төрле гореф-гадәтләр, йола һәм традицияләрдән күренешләр, өзекләр күрсәтү һәм тыңлату бик нәтиҗәле.

Сайланган темаларга ка-

раган сорауларга җавап бирү, күрсәтмәлелекләр кулланып әңгәмә үткәрү, табышмаклар әйтешү, еш кына халык авыз иҗаты жанрларына мөрәҗәгать итү, мәкальләрнең һәм фразеологизмнарның асылына төшенә белергә өйрәтү, дәрес-викториналар, дәрес-ярминкәләр, дәрес-экскурсияләр, кроссвордалар чишү, төзү һ.б. кебек эш төрләрен дә кулланырга була.

Дәрестә укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап, газета-журнал һәм башка матбугат чараларыннан файдалану, алардагы хикәяләр, экиятләр, табышмаклар белән танышу да тәрбияви роль уйный.

Милли мәдәни компонентлар дәрселәрдә генә түгел, ә дәрестән тыш чараларда һәм кичәләрдә дә тәкъдим ителә ала. Мондый кичәләрдә татар балалары белән рус балалары да беррәттән катнаша ала.

Телгә өйрәтүнең төп юнәлешләре методикада төрлечә булган; тарихта интуитив, аңлы, катнаш һ.б. юнәлешләр мәгълүм. Соңгы берничә дистә еллар эчендә шәхеснең коммуникатив эшчәнлегенә нигезләнгән юнәлеш өстенлек алып килә. Бу юнәлеш дөнья һәм рус теле методикасында башка милләт халыкларына чит ил теле укытуда актив кулланыла. Аның төп үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: телгә өйрәтүнең үзәгендә укучы укыту эшчәнлегенең субъекты буларак яши. Димәк, дәресләрнең максаты, аңа ирешү юллары укучының мәнфәгатьләрен һәм шәхси, милли, яшь үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнергә тиеш. Телгә өйрәтү процессы, уку эшчәнлеге буларак оештырылып, укучылар конкрет укыту максатларын куеп, аны хәл итү юнәлешендә эш итәргә тиешләр. Бу юнәлештә укыту тел дәресләрен аралашуга, телне фикерләр алышу чарасы буларак файдалануга өйрәтүне күз алдында тота. Моның өчен укучыларда аралашу ихтыяҗы булдырыла, аның ярдәмендә һөнәри һәм гомуммәдәни әһәмиятле мәгълүмат алу теләген уяту итеп куела.

Болай укыту заманча укыту процессына куелган төп таләпләрне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә: укытучы аралашуны оештыручы көч буларак эшли; дәрестә аралашу процессына якын торган күнегүләр файдаланыла; грамматик форма һәм аның сөйләмдәге функцияләрен өйрәтү янәшә алып барыла: проблемалы бурычлар куелып, алар хәл ителә; күмәк эш формалары кулланыла; укытучы белән укучы арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнаша; шәхеснең үзенчәлекләрен истә

тотып эшләү аның эчке резервларын активлаштыра һәм укыту эшчәнлегенең нәтиҗәле булуын билгели.

Сөйләм материалын сөйләм үрнәкләре, типик фразалар, аралашу һәм ситуация темалары, текстлар тәшкил итә. Темалар сөйләм ситуацияләре аша ачыклана.

Телгә өйрәтүнең эчтәлегенә тел материалы белән эшләү кагыйдәләрен белү дә керә. Димәк, күпмедер күләмдә телдәге кагыйдәләрне белү дә кирәк. Ләкин кагыйдәләр өйрәнеп кенә телне белеп, сөйләшергә өйрәнеп булмый. Безнең мәктәпләрдә күпме еллар чит ил телләре – инглиз, немец, француз телләре укытылып килде, ләкин укучылар бу телләрдә сөйләшә алмады, чөнки күбрәк кагыйдә өйрәнәләр иде, ә сөйләшер өчен грамматик кагыйдә өйрәтү генә җитми.

Телгә өйрәнүнең төп максаты – алган белемнәр нигезендә сөйләм күнекмәләре формалаштыру.

Сөйләм күнекмәләренә ия булганда тел аңлы рәвештә кулланыла. Тиз җавап биргәндә, сөйләм тотрыклы булганда, аңлы рәвештә эшләгәндә, ситуация үзгәреп күнекмә үзгәртелә алганда, күнекмәләр формалашкан дип санала ала.

Күнекмәләр һәм алган белемне файдалану нигезендә телне белү барлыкка килә. Телне белгәндә генә, коммуникатив (аралашу) максатлары хәл ителә: сөйләшә, тыңлап аңлый, укый һәм яза ала торган кешене телне белүче дип әйтәләр.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, чит телгә өйрәткәндә, укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерүгә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңа агымда югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу.

Әдәбият:

1. Гәрәева Г.Х. Уртаклашыр тәҗрибәм бар. Казан : Яңалиф, 2005. Б.7-27.

2. Гәрәев Ф.М. Безнең гасырның 20 нче елларында татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре // Гыйльми язмалар, 1997. №2. Б.165.

3. Рамазанова Д.Б. Татар теле укытуның кайбер мәсьәләләре // Мәгариф. 1997. №8. 41 б.

4. Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному. Санкт-Петербург : Просвещение, 2001. 52 с.